ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 февраль 2025 ел № 1275

«85 нче психологик-медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесенең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2019 елның 1 ноябрендәге 998 номерлы Карары, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) «85 нче психологик-медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) «85 нче психологик-медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне 2 нче кушымтада каралганча.

2. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылган көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 19 февралендәге
1275 номерлы карарына
1 нче кушымта

«85 нче психологик-медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә «85 нче психологик-медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба – учреждение) җитәкчесенең һәм хезмәткәрләренең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләү шартларын һәм күләмен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

2. Әлеге нигезләмәдә төп төшенчәләр һәм билгеләмәләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексындагы мәгънәләрдә кулланыла.

3. Учреждениенең мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт хакы (хезмәткәрнең хезмәтенә түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

1) вазыйфаи окладлар;

2) компенсация характерындагы түләүләр;

3) стимуллаштыру характерындагы түләүләр.

4. Мәгариф хезмәткәренең, мәдәният хезмәткәренең, медицина хезмәткәренең елга бер тапкыр бирелә торган яки башка ялда булганда, вакытлыча хезмәткә яраксызлык чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларда профиль буенча эш стажы артуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә, ведомствоның аерымлык билгесе белән бүләкләнүгә бәйле рәвештә, хезмәткә түләү күләме үзгәрүгә хокукы барлыкка килгәндә, хезмәткә түләү күләмен үзгәртү күрсәтелгән чорлардан соң гамәлгә ашырыла.

5. Учреждение җитәкчесе:

1) белем һәм педагогик эш стажы (белгечлек буенча, билгеле бер вазыйфада эшләү) турындагы документларны Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының Бердәм квалификация белешмәлеген, «Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация характеристикалары» бүлеген раслау турында» 2010 елның 26 августындагы 761н номерлы приказы белән расланган таләпләргә туры килүен тикшерә;

2) ел саен хезмәткәрләргә тариф исемлекләре төзи һәм раслый;

3) хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләмен вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җаваплы.

2 бүлек. Учреждениенең мәгариф хезмәткәренең, мәдәният хезмәткәренең, медицина хезмәткәренең база окладларын билгеләү

6. Учреждениенең мәгариф хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Уку-укыту бүлеге секретаре | 21 473 |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Кече тәрбияче | 21 583 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура буенча инструктор | 22 663 |
| | Музыка җитәкчесе | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Педагог-оештыручы | 22 758 |
| | Социаль педагог | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Тәрбияче | 22 858 |
| | Педагог-психолог | |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| | Методист | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | 22 958 |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | |
| | Укытучы-дефектолог | |
| | Укытучы-логопед (логопед) | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен | 23 008 |

| | | |
|---|---|---|
| | гамәлгә ашыручы оешмалар, гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы структур бүлекчә (бүлек, лаборатория, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-производство) мастерское һәм башка структур бүлекчәләр мөдире (башлыгы) (икенче квалификация дәрәҗәсенә караган структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | |

7. Учреждениенең мәдәният хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 22 820 |
| Түгәрәк, һәвәскәрләр берләшмәсе, кызыксыну буенча клуб җитәкчесе | |
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Китапханәче | 23 320 |
| Тавыш операторы | |

8. Учреждениенең медицина хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Медицина регистраторы | 22 121 |

| | | |
|---|---|---|
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы (медбрат) | 23 121 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медбрат) | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы (өлкән медбрат) | 24 821 |
| «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәсенә караган табиб-белгечләрдән тыш) | 26 521 |

3 бүлек. Учреждениенең мәгариф хезмәткәрләрнең, мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең база оклады өчен сәгатьләр нормасы

9. Эш вакытының озынлыгы (педагогик эш сәгатьләре нормалары) Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Педагогик хезмәткәрләрнең эш вакыты озынлыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары) һәм педагогик хезмәткәрләрнең хезмәт шартнамәсендә аталган укыту йөкләнешен билгеләү тәртибе турында» 2014 елның 22 декабрендәге 1601 номерлы приказы белән билгеләнгән.

Мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең эш вакыты озынлыгы Россия Федерациясе Хезмәт кодексы белән билгеләнә.

4 бүлек. Учреждениенең мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе

10. Учреждениенең мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_{fk}}{H_N} + P,$$

монда:

$O_b$ - учреждениенең мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең база окладының күләме;

$H_{fk}$ - учреждениенең мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләре тарафыннан эшләнгән фактик сәгатьләр саны;

$H_N$ – учреждениенең мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең база оклады өчен сәгатьләр нормасы;

P – китап бастыру продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация, педагогик хезмәткәрләргә укыту йөкләнешенә пропорциональ, әмма төп эш урыны буенча бер ставкадан артмаган күләмдә билгеләнә.

## 5 бүлек. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

11. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә мәгариф хезмәткәрләрен, мәдәният хезмәткәрләрен, медицина хезмәткәрләрен сыйфатлы хезмәт нәтиҗәләренә стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен кызыксындыруга юнәлдерелгән түләүләр керә.

12. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) квалификация категориясе өчен түләүләр;

2) мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләүләр;

3) профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;

4) интенсив хезмәт өчен түләүләр;

5) премия һәм башка кызыксындыру түләүләре;

6) башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр.

13. Учреждениенең мәгариф хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгеләү тәртибе һәм күләмнәре:

1) квалификация категориясе ($B_{kk}$) өчен түләүләр мәгариф хезмәткәрләренә, гамәлдәге квалификация категориясе булган очракта, квалификация категориясе гамәлдә булу срогы чикләрендә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - учреждениенең мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ - квалификация категориясе өчен өстәмәнең күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмәнең күләме 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица

Квалификация категориясе өчен өстәмәләрнең күләме

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмәнең күләме, процент |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 5,0 |
| | югары квалификация категориясе | 6,0 |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 6,0 |
| | югары квалификация категориясе | 8,0 |
| Өченче | беренче квалификация категориясе | 6,5 |
| | югары квалификация категориясе | 10,0 |
| Дүртенче | беренче квалификация категориясе | 8,0 |
| | югары квалификация категориясе | 12,0 |

| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
|---|---|---|
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 6,0 |
| | югары квалификация категориясе | 8,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән башкарыла.

2) мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре (Bpz) булган өчен түләүләр структур бүлекчәләрнең беренче һәм икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал, педагогик хезмәткәрләр һәм җитәкчеләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәгариф хезмәткәрләре вазыйфалары буенча бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

монда:

$O_d$ - учреждениенең мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи окладьы;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре өчен өстәмәнең күләме.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре өчен өстәмәнең күләме җиде процент тәшкил итә.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре (Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының мактаулы исемнәре) өчен өстәмәнең күләме алты процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе ведомство бүләкләре, Россия федератив Социалистик Республикасыведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалары Союзы ведомство бүләкләре, Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы союздаш республикалар ведомство бүләкләре өчен өстәмәнең күләме дүрт процент тәшкил итә.

Мактау грамотасы өчен өстәмәнең күләме ике процент тәшкил итә. Мактау грамотасы өчен өстәмә, бүләкләнүче мәгариф хезмәткәрләренә Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының) ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе нигезендә, Россия Федерациясе мәгариф министры (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры, Россия Федерациясе мәгариф министры) приказы нигезендә билгеләнә.

«Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе өчен өстәмәнең күләме ике процент тәшкил итә. «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе өчен өстәмә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) приказы нигезендә билгеләнә.

Мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре исемлеге әлеге нигезләмәнең 1 нче кушымтасында китерелгән.

Мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләү күләмен билгеләү мактаулы исем һәм ведомство бүләге бирелгән көннән башкарыла. Хезмәткәрләргә ике һәм аннан күбрәк мактаулы исем һәм (яки) ике һәм аннан күбрәк

ведомство бүләге булган өчен түләү, хезмәткәрнең сайлавы буенча, аларның берсе буенча билгеләнә.

3) профиль буенча эш стажы өчен түләүләр профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

монда:

$O_d$ - учреждениенең мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ - п рофиль буенча эш стажы өчен өстәмәнең күләме.

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмәнең күләме 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмәләрнең күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркем | Өстәмәнең күләме, процент |
|---|---|---|---|
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | беренче-икенче | 4 елдан 10 елга кадәр | 1,0 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,0 |
| | | 15 елдан артык | 3,0 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | беренче - дүртенче | 2 елдан 6 елга кадәр | 2,0 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 3,0 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | | 15 елдан артык | 4,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | беренче - өченче | 2 елдан 6 елга кадәр | 2,0 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 3,0 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | | 15 елдан артык | 4,0 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү), стажны раслаучы документлар оешмада булса, эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән яки стажны раслый торган документ тапшырылган көннән башкарыла.

Мәгариф һәм башка оешмаларда педагогик, җитәкче һәм методик эш педагогик эш стажына керә һәм 3 нче таблица нигезендә исәпләнә.

3 нче таблица

Эш вакыты мәгариф хезмәткәрләренең педагогик стажына кертелә торган оешмалар һәм вазыйфалар исемлеге

| Оешма исеме | Вазыйфаның исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Белем бирү оешмалары (шул исәптән югары белем бирү оешмалары, хәрби югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм хәрби һөнәри белем бирү оешмалары, өстәмә һөнәри белем (белгечләрнең квалификациясен күтәрү) оешмалары;<br><br>медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары (балалар йортлары, балалар санаторийлары) | Укытучылар, укытучы- дефектологлар, укытучылар-логопедлар (логопедлар), укытучы-оештыручылар (тормыш иминлеге нигезләре, хәрби чакырылышка кадәрге әзерлек), физик тәрбия җитәкчеләре, өлкән мастерлар, производствога өйрәтү мастерлары (шул исәптән транспорт чараларын йөртергә, авыл хуҗалыгы машиналарында эшләргә өйрәтү, язу машиналарында һәм башка оештыру техникасында эшләргә өйрәтү), өлкән методистлар, методистлар, өлкән инструктор-методистлар, инструктор-методистлар (шул исәптән физик культура һәм спорт, туризм буенча), концертмейстерлар, музыка җитәкчеләре, өлкән тәрбиячеләр, сыйныф тәрбиячеләре, социаль педагоглар, педагог-психологлар, педагог-оештыручылар, өстәмә белем бирү педагоглары, өлкән тренер-укытучылар, тренер-укытучылар, өлкән әйдаманнар (пионервожатыйлар), физкультура инструкторлары, хезмәт инструкторлары, директорлар (башлыклар, мөдирләр), укыту, укыту-тәрбия, укыту-производство, тәрбия, мәдәни-тәрбия эшләре, җитештерү буенча укыту (эш), чит тел буенча, укыту-очучылар әзерләү, гомуми белем бирү әзерлеге буенча, режим буенча директор урынбасарлары (башлыклар, мөдирләр), уку-укыту бүлеге мөдирләре,(башлыклары): практика, укыту-консультация пунктлары, логопед пунктлары, эшчәнлеге белем бирү (тәрбия) процессы, методик тәэмин ителеш белән бәйле булган башка структур бүлекчәләр, интернатлар, бүлекләр, бүлекләр, лабораторияләр, кабинетлар,секцияләр, филиаллар, курслар һәм башка структур бүлекчәләр, режим буенча өлкән дежурлар, режим буенча дежурлар, аккомпаниаторлар, мәдәни оештыручылар, экскурсоводлар; профессор-укытучылар составы; |
| Барлык исемдәге методик (укыту-методик) оешмалар | Җитәкчеләр, аларның урынбасарлары, сектор, кабинетлар, лабораторияләр, бүлекләр мөдирләре; |

| | |
|---|---|
| (ведомство буйсынуына бәйсез рәвештә) | эшчәнлеге методик тәэмин ителеш белән бәйле фәнни хезмәткәрләр; өлкән методистлар, методистлар |
| Мәгариф белән идарә итү органнары һәм белем бирү оешмалары җитәкчелеген гамәлгә ашыручы органнар (структур бүлекчәләр) | Җитәкче, инспекторлык, методик вазыйфалар, инструкторлык, шулай ук белгечләрнең башка вазыйфалары (икътисад, финанс, хуҗалык эшчәнлеге, төзелеш, тәэмин итү, эш башкару белән бәйле вазыйфаларда эшләүдән тыш) |
| Производствода кадрлар әзерләү һәм квалификация күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче оешмаларның, республика башкарма хакимият органнарының техник белем бирү бүлекләре (бюролары), кадрлар бүлекләре | Штаттагы укытучылар, җитештерүдә эшчеләрне производствога өйрәтү мастерлары, эшчәнлеге әзерлек һәм квалификация күтәрү мәсьәләләренә бәйле җитәкче, инспектор, инженер, методик вазыйфалар |
| Россия оборона спорт-техник оешмасы һәм гражданнар авиациясенең белем бирү оешмалары | Җитәкче, команда-очу, команда-инструктор, инженер-инструктор, инструктор, инструктор һәм укытучылар составлары, производствога өйрәтү мастеры, борт инженер-инструкторлары, очу әзерлеге буенча методистлар (борт инженерлары, борт операторлары, борт радистлары, икенче пилотлар, һава суднолары командирлары, штурманнар) |
| Предприятиеләр һәм оешмаларның тулай торaклары, торак-эксплуатация оешмалары, яшьләр торак комплекслары, балалар кинотеатрлары, яшь тамашачы театрлары, курчак театрлары, мәдәни-агарту оешмалары һәм балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү буенча предприятиеләр һәм оешмалар бүлекчәләре | Тәрбиячеләр, педагог-оештыручылар, педагог-психологлар (психологлар), балалар һәм яшүсмерләр өчен өстәмә белем бирү педагоглары (түгәрәк җитәкчеләре), инструкторлар һәм инструктор-методистлар, тренер-укытучылар һәм балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү буенча башка белгечләр, балалар бүлекләре, секторлар мөдирләре |
| Төзәтү колонияләре, тәрбия колонияләре, тикшерү изоляторлары һәм төрмәләр, дәвалау-төзәтү оешмалары | Педагогик белеме булган очракта, түбәндәге вазыйфаларда эш (хезмәт): тәрбия эшләре буенча башлык урынбасары, отряд башлыгы, өлкән инспектор, гомуми белем бирү (уку-укыту) буенча инспектор, өлкән инспектор-методист һәм инспектор-методист, өлкән инженер һәм җитештерү-техник белем бирү буенча инженер, өлкән мастер |

| | |
|---|---|
| | һәм производствога өйрәтү буенча мастер, саклау һәм режим буенча өлкән инспектор, укыту-техник кабинет мөдире, психолог. |
| Искәрмә:<br>Педагогик эш стажына түбәндәгеләр керә:<br>Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау оешмаларының оештыру-методик бүлеге методистлары, медицина оешмаларында һәм өлкәннәр өчен социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмаларда укытучы-дефектологлар, логопедлар, тәрбиячеләр сыйфатында эшләү вакыты;<br>башка оешмаларда эшләү вакыты, Совет Социалистик Республикалар Союзы Кораллы көчләрендә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итү, югары белем бирү мәгариф оешмаларында һәм урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында уку вакыты түбәндәге тәртиптә:<br>педагогик хезмәткәрләргә педагогик эш стажына бернинди шартларсыз һәм чикләүләрсез кертелә;<br>контракт буенча хәрби хезмәттә булу вакытын хәрби хезмәтнең бер көнен бер эш көне исәбеннән, ә чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булу вакытынбер хәрби хезмәт көнен ике эш көне исәбеннән;<br>фильмотека мөдире һәм фильмотека методисты вазыйфасында эшләү вакыты;<br>педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эш стажына түбәндәге чорлар кертелә, әгәр аерым һәм тулаем алынган бу чорларда турыдан-туры алардан алда һәм турыдан-туры алардан соң педагогик эшчәнлек алып барылган очракта;<br>Совет Социалистик Республикалар Союзы һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә офицер, сержант, старшина составлары, прапорщиклар һәм мичманнар вазыйфаларында хезмәт итү вакыты (шул исәптән Эчке эшләр министрлыгы гаскәрләрендә, куркынычсызлык гаскәрләрендә һәм органнарында), контракт буенча һәм чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булу вакытыннан тыш;<br>Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре профсоюзының (мәгариф, югары мәктәп һәм фәнни оешмалар) территориаль оешмалар аппаратларында (комитетларда, советларда) җитәкче, инспекторлык, инструкторлык һәм башка белгечлек вазыйфаларында; профсоюз органнарында сайланулы вазыйфаларда; педагогик җәмгыятьләрдә һәм Балалар фонды идарәләрендә инструкторлык һәм методик вазыйфаларда; Укытучылар (халык мәгарифе, һөнәри техник белем бирү хезмәткәре) йорты директоры (мөдире) вазыйфасында; балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрендә яки балигъ булмаганнарны социаль-хокукый яклау бүлекләрендә, Эчке эшләр органнарының хокук бозуларны кисәтү бүлекчәләрендә (балигъ булмаганнар белән эшләү буенча инспекцияләрдә, милиция балалар бүлмәләрендә). | |

Аерым категория педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эш стажына белем бирү оешмасындагы эш профиленә яки укытыла торган предмет (курс, дисциплина, түгәрәк) профиленә туры килә торган белгечлек (һөнәр) буенча оешмаларда эшләү вакыты һәм Совет Социалистик Республикалар Союзы һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итү вакыты кертелә:

укытучы-оештыручыларга (тормыш эшчәнлеге иминлеге, хәрби хезмәткә чакырылуга кадәр әзерлек нигезләре);

физик тәрбия укытучыларына, физик тәрбия җитәкчеләренә, физкультура буенча инструкторларга, инструктор-методистларга (өлкән инструктор-методистларга), тренер-укытучыларга (өлкән тренер-укытучыларга);

укытучыларга, хезмәт (һөнәри) укыту, технология, сызым, сынлы сәнгать, информатика, махсус дисциплиналар, шул исәптән аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган гомуми белем бирү оешмаларының (сыйныфларының) махсус дисциплиналары укытучыларына;

өстәмә белем бирү педагогларына;

эксперименталь белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә;

педагог-психологларга;

методистларга;

музыка һәм сәнгать гомуми белем бирү оешмаларының махсус дисциплиналар укытучыларына.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, балалар йортлары тәрбиячеләренә (өлкән тәрбиячеләренә) педагогик стажга мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының ясле төркеме шәфкать туташы вазыйфасында, бала йортларының пост шәфкать туташы вазыйфасында эшләү вакыты, ә ясле төркемнәр тәрбиячеләренә - медицина вазыйфаларында эшләү вакыты кертелә.

Тәрбияче ярдәмчесе һәм кече тәрбияче вазыйфаларында эшләгән чорда хезмәткәрнең педагогик белеме булган яки ул югары белем бирү оешмасында яки һөнәри белем бирү оешмасында укыган очракта, әлеге вазыйфаларда эшләү вакыты педагогик эш стажына керә.

Күләме (бер яки берничә белем бирү оешмасында) уку елы дәвамында 180 сәгатьтән дә ким булмаса, белем бирү оешмаларында төп эштән тыш сәгатьләп түләү шартларында башкарыла торган педагогик эш вакыты оешма хезмәткәрләренең педагогик стажына кертелә.

Шул ук вакытта педагогик стажга педагогик эш башкарган айлар гына кертелә.

Оешмада эшләүнең һәм Совет Социалистик Республикалар Союзы һәм Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә хезмәт итүнең эш, укытыла торган предмет (курс, дисциплина, түгәрәк) профиленә туры килүе турындагы конкрет мәсьәләне хәл итү хокукы, профсоюз органы белән килештереп, белем бирү оешмасы җитәкчесенә бирелә.

14. Учреждениенең мәдәният хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләрне билгеләү тәртибе һәм күләмнәре:

1) квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) тариф-квалификация характеристикалары нигезендә, һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләрен бирүне күздә тоткан белгечлекләр буенча эшләүче аерым мәгариф һәм спорт оешмаларының мәдәният хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - учреждениенең мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ - квалификация категориясе өчен өстәмәнең күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмәнең күләме 4 нче таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (оешма) приказының датасы нигезендә башкарыла.

4 нче таблица

Квалификация категориясе өчен өстәмәләрнең күләме

| Квалификация категориясе | Өстәмәнең күләме, процент |
|---|---|
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация категориясе | 5,0 |
| Югары квалификация категориясе | 8,0 |

2) мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) мәдәният хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ – аерым мәгариф һәм спорт оешмаларының мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен өстәмәнең күләме.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмәнең күләме алты процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмәнең күләме җиде процент тәшкил итә.

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге нигезләмәгә 2 нче кушымтада китерелгән.

Мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләү күләмен билгеләү мактаулы исем һәм ведомство бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан күбрәк мактаулы исеме һәм (яки) ике һәм аннан күбрәк ведомство бүләге булган хезмәткәрләргә түләү, хезмәткәрнең сайлавы нигезендә, аларның берсе буенча билгеләнә.

3) профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$) хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларының үтәлешен исәпкә алып, профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә, һөнәри-квалификация төркемнәре киселешендә, учреждениенең мәдәният хезмәткәрләренә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - учреждениенең мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладында;

$D_s$ - профиль буенча эш стажы өчен өстәмәнең күләме.

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмәнең күләме 5 нче таблицада китерелгән.

5 нче таблица

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмәләрнең күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмәнең күләме, процент |
|---|---|---|
| Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,0 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 1,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,0 |
| | 15 елдан артык | 2,5 |
| Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,0 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 2,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | 15 елдан артык | 4,0 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү), стажны раслаучы документлар оешмада булса, профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән яки стажны раслый торган документ тапшырылган көннән башкарыла.

15. Учреждениенең медицина хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләрне билгеләү тәртибе һәм күләмнәре:

1) квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) тариф-квалификация характеристикалары нигезендә, һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләрен бирүне күздә тоткан белгечлекләр буенча эшләүче аерым мәгариф һәм спорт оешмаларының медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - учреждениенең медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ - квалификация категориясе өчен өстәмәнең күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмәнең күләме 6 нчы таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (оешма) приказының датасы нигезендә башкарыла.

6 нчы таблица

Квалификация категориясе өчен өстәмәләрнең күләме

| Квалификация категориясе | Өстәмәнең күләме, процент |
|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 3,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 6,0 |

| | |
|---|---|
| Югары квалификация категориясе | 10,0 |
| Табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 6,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 10,0 |
| Югары квалификация категориясе | 20,0 |

2) мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) учреждениенең медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - учреждениенең медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен өстәмәнең күләме.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономяле республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмәнең күләме алты процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмәнең күләме җиде процент тәшкил итә.

Медицина хезмәткәрләренә түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге нигезләмәгә 3 нче кушымтада китерелгән.

Мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләү күләмен билгеләү мактаулы исем һәм ведомство бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан күбрәк мактаулы исеме һәм (яки) ике һәм аннан күбрәк ведомство бүләге булган хезмәткәрләргә түләү, хезмәткәрнең сайлавы нигезендә, аларның берсе буенча билгеләнә.

3) учреждениенең медицина хезмәткәрләренә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$) профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә, һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - учреждениенең медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ - профиль буенча эш стажы өчен өстәмәнең күләме.

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме 7 нче таблицада китерелгән.

7 нче таблица

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмәләрнең күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмәнең күләме, процент |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Табиблар һәм провизорлар | 3 елдан 5 елга кадәр | 5,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 7,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 9,0 |
| | 15 елдан артык | 10,0 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү), стажны раслаучы документлар оешмада булса, профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән яки стажны раслый торган документ тапшырылган көннән башкарыла.

4) хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр ($B_{sr}$) медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sr} = O_d \times \frac{D_{sr}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - учреждениенең медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sr}$ - хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмәнең күләме.

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмәнең күләме 8 нче таблицада китерелгән.

8 нче таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмәләрнең күләме

| Һөнәри-квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмәләр диапазоны, процент |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | өченче | 3,0 |
| | бишенче | 5,0 |
| Табиблар һәм провизорлар | беренче-икенче | 3,0 |

16. Пермияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре учреждениенең мәгариф хезмәткәрләренә, мәдәният хезмәткәрләренә, медицина хезмәткәрләренә, юбилей даталары, аерымлык билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, бүләкләр, исемнәр алу сәбәпле һәм оешманың локаль норматив актлары һәм коллектив шартнамәләре белән билгеләнгән башка нигезләр буенча, төп эш урыны һәм төп вазыйфасы («укытучы-

дефектолог», «укытучы-логопед (логопед)» вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) буенча аерым чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.

Эш йомгаклары буенча премия һәм башка кызыксындыру түләүләрен күләме, тәртибе һәм аларны гамәлгә ашыру шартлары оешманың локаль норматив актлары һәм коллектив шартнамәләр белән билгеләнә.

Учреждение хезмәткәрләренә премия түләүләренә каралган хезмәткә түләү фондының күләме предмет, методик яки цикл комиссияләре, методик берләшмәләр җитәкчелеге өчен, уку кабинетлары, лабораторияләр, музейлар белән җитәкчелек иткән өчен, эшчәнлек үзенчәлекләре өчен төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча хезмәткәрләргә («укытучы-дефектолог», «укытучы-логопед (логопед)» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) окладлар (вазыйфаи окладлар), стимуллаштыру характерындагы түләүләргә, компенсация характерындагы түләүләргә каралган хезмәткә түләү фондының кимендә ике процентын тәшкил итә.

17. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр учреждениеләрнең мәгариф хезмәткәрләренә, мәдәният хезмәткәрләренә, медицина хезмәткәрләренә төп эш урыны буенча («укытучы-дефектолог», «укытучы-логопед (логопед)» вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) билгеле вакыт вакыт чорындагы эш нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләменә йогынты ясаучы төп критерий булып, аерым мәгариф һәм спорт оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренә, мәдәният хезмәткәрләренә, медицина хезмәткәрләренә эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү тора.

Учреждениенең мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары оешма җитәкчесе тарафыннан расланa. Аерым мәгариф һәм спорт оешмаларының мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының зурлыгы, түләүләрне гамәлгә ашыру шартлары оешма алдына куелган бурычлар нигезендә ел саен билгеләнә.

Учреждениенең мәгариф хезмәткәрләренә, мәдәният хезмәткәрләренә, медицина хезмәткәрләренә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләрнең күләме, тәртибе һәм гамәлгә ашыру шартлары оешманың локаль норматив актлары һәм коллектив шартнамәләр белән билгеләнә.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр ($B_{kj}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kj} = \frac{FOT_k}{\sum_{i=1}^{n}\sum_{j=1}^{m}\left(I_{ij} \times K_i\right)} \times \sum_{i=1}^{n}\left(I_{ij} \times K_i\right),$$

монда:

$FOT_k$ - башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүгә каралган хезмәткә түләү фонды;

$I_{ij}$ - i хезмәткәрнең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең нормалаштырылган i критерие;

$K_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең i критериеның чагыштырма авырлык коэффициенты;

n - эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары саны;

m - учреждение хезмәткәрләренең саны.

Эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийларын нормалаштыру төрле зурлыктагы нәтиҗәлелек критерийларын чагыштыруны тәэмин итә. Нормалаштыру - эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критерие (иң яхшысы һәм иң начары) күрсәткечләренең диапазонын сайлаудан гыйбарәт, шуларның берсе нульгә тигезләнгән критерийга, икенчесе - бердәй күрсәткечкә туры килә. Нәтиҗәлелек критериеның фактик зурлыгы эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие

билгесе диапазоны чикләрендә булганда, эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие нульдән алып бергә кадәр билгеләнә. Нәтиҗәлелек критериеның фактик зурлыгы иң начар күрсәткечтән түбәнрәк булганда, нормаллаштырылган критерийның зурлыгы нульгә тигез, иң яхшы күрсәткечтән югары булганда бергә тигез була.

Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критереның зурлыгы эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критерие зурлыгына бәйлелеге турыдан-туры (уңай динамика критерий зурлыгының артуы белән билгеләнә) һәм кире (уңай динамика критерий зурлыгының кимүе белән билгеләнә) булырга мөмкин.

Аның зурлыгы критерий зурлыгына турыдан-туры бәйлелектә булганда, нормалаштырылган критерий ($I_i$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

монда:

$Fi_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның фактик зурлыгы;

$M_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң яхшы зурлыгы;

$L_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң начар зурлыгы.

Аның зурлыгы критерий зурлыгына кире бәйлелектә булганда, эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие ($I_i$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = 1 - \frac{FI_i - L_i}{L_i - M_i},$$

монда:

$Fi_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның фактик зурлыгы;

$M_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң яхшы зурлыгы;

$L_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң начар зурлыгы.

Авырлык коэффициентлары белән эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критериенең өстенлек дәрәҗәсе билгеләнә. Иң өстенлекле критерийга иң зур коэффициент бирелә.

Чагыштырма авырлык коэффициенты ($K_i$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_i = \frac{VK_i}{\sum_{i=1}^{n} VK_i},$$

монда:

$Vk_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең i критериеның авырлык коэффициенты.

Аерым мәгариф һәм спорт оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелек критерийлары буенча авырлык коэффициентларының иң чик гомуми күләме 9-11 нче таблицаларда китерелгән.

9 нчы таблица

Мәгариф хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелек критерийлары буенча авырлык коэффициентларының иң чик гомуми күләме

| № т/б | Вазыйфаның исеме | Авырлык коэффициентларының иң чик гомуми күләме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| 1.Беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| 1.1. | Уку-укыту бүлеге секретаре | 5 |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| 2.1. | Кече тәрбияче | 35 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 3.1. | Физик культура буенча инструктор | 45 |
| 3.2. | Музыка җитәкчесе | 45 |
| 3.3. | Педагог-оештыручы | 50 |
| 3.4. | Социаль педагог | 50 |
| 3.5. | Тәрбияче | 55 |
| 3.6. | Методист | 55 |
| 3.7. | Педагог-психолог | 55 |
| 3.8. | Өлкән инструктор-методист | 55 |
| 3.9. | Өлкән методист | 60 |
| 3.10. | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | 60 |
| 3.11. | Укытучы-дефектолог | 60 |
| 3.12. | Укытучы-логопед (логопед) | 60 |
| 4. Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 4.1. | Структур бүлекчә мөдире (җитәкчесе): кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (производствога өйрәтү) мастерское һәм гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү белем бирү программасын гамәлгә ашыручы башка структур бүлекчәләр (икенче квалификация дәрәҗәсенә караган структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | 65 |

10 нчы таблица

Мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелек критерийлары буенча авырлык коэффициентларының иң чик гомуми күләме

| № | Вазыйфаның исеме | Авырлык |
|---|---|---|

| т/б | | коэффициентларының иң чик гомуми күләме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 1.1. | Аккомпаниатор | 35 |
| 1.2. | Мәдәни чаралар оештыручы | 35 |
| 1.3. | Түгәрәк, һәвәскәрләр берләшмәсе, кызыксыну буенча клуб җитәкчесе | 35 |
| 2. Әйдәүче звено мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 2.1. | Китапханәче | 40 |
| 2.2. | Тавыш операторы | 40 |

11 нче таблица

Медицина хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелек критерийлары буенча авырлык коэффициентларының иң чик гомуми күләме

| № т/б | Вазыйфаның исеме | Авырлык коэффициентлары ның иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| 1.1. | Медицина регистраторы | 35 |
| 1.2. | Шәфкать туташы (медбрат) | 40 |
| 1.3. | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медбрат) | 40 |
| 1.4. | Өлкән шәфкать туташы (өлкән медбрат) | 50 |
| 2. Табиб һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 2.1. | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәсенә караган табиб-белгечләрдән тыш) | 60 |

42. Учреждениедә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр фонды ($FOT_k$) формалаштырыла, аның күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT_k = FOT_{do} \times \frac{D_k}{100\%},$$

монда:

$FOT_{do}$ - төп эш урыны буенча вазыйфаи окладлар буенча учреждениенең мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү фонды («укытучы-дефектолог», «укытучы-логопед (логопед)») вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш);

$D_k$ - башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр өчен хезмәткә түләү фондының күләме.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр өчен хезмәткә түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме төп эш урыны буенча хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары буенча учреждение хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү фондының биш проценты күләмендә кабул ителә («укытучы-дефектолог», «укытучы-логопед (логопед») вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш).

## 6 бүлек. Компенсация характерындагы түләүләр

18. Учреждениенең мәгариф хезмәткәрләренә, мәдәният хезмәткәрләренә, медицина хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

1) предмет, методик яки цикл комиссияләре, методик берләшмәләр белән җитәкчелек иткән өчен компенсация характерындагы түләүләр;

2) уку кабинетлары, лабораторияләр, музейлар белән җитәкчелек иткән өчен компенсация характерындагы түләүләр;

3) эшчәнлек үзенчәлеге өчен компенсация характерында түләүләр;

4) зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә түләүләр;

5) нормаль эш шартларыннан тайпылган шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш башкарылган эштә, төнлә һәм нормаль эш шартларыннан тайпылган башка шартларда эшләр башкарганда) эшләү өчен компенсация характерындагы түләүләр.

19. Компенсация характерындагы түләүләр, аларның күләмнәре һәм гамәлгә ашыру шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә, коллектив шартнамәләр, локаль норматив актлар, хезмәт шартнамәсе белән билгеләнә.

20. Предмет, методик яки цикл комиссияләре, методик берләшмәләр белән җитәкчелек иткән өчен компенсация характерындагы түләүләр ($B^{rk}_{nz}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B^{rk}_{nz} = O_b \times \frac{D_{rk}}{100\%},$$

монда:

$O_b$ - учреждениенең педагогик хезмәткәрләренең база окладының күләме;

$D_{rk}$ - предмет, методик яки цикл комиссияләре, методик берләшмәләр белән җитәкчелек иткән өчен өстәмәнең күләме өч процент тәшкил итә.

Педагогик хезмәткәр тарафыннан берничә комиссия, берләшмә белән җитәкчелек итүне тәэмин иткәндә түләүләр күләме һәр комиссия, берләшмә буенча түләүләр суммасы буларак исәпләнә.

21. Аерым мәгариф һәм спорт оешмаларының уку кабинетлары, лабораторияләре, музейлары белән җитәкчелек иткән өчен компенсация характерындагы түләү 444 сум тәшкил итә.

Кабинет белем бирү процессын җиһазландыруга карата расланган таләпләрнең кимендә 50 проценты күләмендә җиһазландырганда, кабинетлар, лабораторияләр белән җитәкчелек итү укыту-методик, дидактик һәм күрсәтмә материалның уку кабинеты паспорты таләпләренә туры килү дәрәҗәсе белән билгеләнә.

Педагогик хезмәткәр тарафыннан берничә уку кабинеты, лаборатория, музей эшен тәэмин иткәндә, әлеге эшне тәэмин итү өчен түләүләр күләме һәр уку кабинеты, лаборатория, музей буенча түләүләр суммасы буларак исәпләнә.

22. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен компенсация характерындагы түләүләр ($B_{sd}$) медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times \frac{D_{sd}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - учреждениенең медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sd}$ - эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмәнең күләме.

Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмәнең күләме 12 нче таблицада китерелгән.

12 нче таблица

Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмәләрнең күләме

| № т/б | Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә билгеләү нигезе | Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Өстәмәнең күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1. | Белем бирү оешмаларында эшләү | урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 17,0 |
| | | табиблар һәм провизорлар | 10,0 |

23. Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә, шулай ук нормаль эш шартларыннан тайпылган шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш башкарылган эштә, төнлә һәм нормаль эш шартларыннан тайпылган башка шартларда эшләр башкарганда) эшләү өчен компенсация характерындагы түләүләр ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_d \times D_{kh} \times \frac{H_{fk}}{H_N},$$

монда:

$O_b$ - учреждениенең мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;

$D_{kh}$ - компенсация характерындагы түләү өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә торган өстәмәнең күләме;

$H_{fk}$ - учреждениенең мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре тарафыннан эшләнгән сәгатьләрнең фактик саны;

$H_N$ - учреждениенең мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең база оклады өчен сәгатьләр нормасы.

Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә хезмәт хакы нормаль хезмәт шартлары булган төрле эш төрләре өчен билгеләнгән окладлар (вазыйфаи окладлар) белән чагыштырганда арттырып, хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә дүрт процент күләмендә билгеләнә.

24. Нормаль шартлардан тайпылган шартларда эшләгән өчен түләү (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш башкарылган эштә, төнлә һәм нормаль шартлардан тайпылган башка шартларда эшләр башкарганда) Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

25. Әлеге оешмада, бүлекчәдә һәм вазыйфада конкрет эш шартларын исәпкә алып, компенсация характерындагы өстәмәләр билгеләнә торган вазыйфалар исемлеге, сайланулы профсоюз органы яки мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре мәнфәгатьләрен якларга вәкаләтле башка орган белән килештереп, һәр оешмада раслана.

## 7 бүлек. Учреждение җитәкчесенең, аның урынбасарларының һәм баш бухгалтерның хезмәт хакын билгеләү тәртибе

26. Учреждение җитәкчесенең, аның урынбасарларының һәм баш бухгалтерның хезмәт хакы вазыйфаи окладлардан, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән гыйбарәт.

27. Учреждение җитәкчесенең вазыйфаи окладлары ($O_d$) хезмәткә түләү төркеменә бәйле рәвештә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_{fk}}{H_N},$$

монда:

$O_b$ - җитәкченең база окладының күләме;

$H_{fk}$ - учреждение җитәкчесе, аның урынбасарлары һәм баш бухгалтер тарафыннан эшләнгән сәгатьләрнең фактик саны;

